2024 елда Мордовия мәктәпләре яны жәйге лагерьларындагы балалар беренче сменада, ә ул 21 кон дәвам итә, яллары файдалы һәм кvнелле vтә.
2024 елдан мәктәп яны лагерьларын оештыруга яна санитар-эпидемиологик таләпләр vз кочено керде. Алар балалар очен кvрсәтелә торган хезмәтләрнен куркынычсызлыгын, унайлылыгын һәм сыйфатын арттыруга юнәлдерелгән. Кон режимы - сәламәтлекне ныгыту, физик һәм ижади сәләтләрне vстерv очен ачык һавада максималь тору. Спорт һәм мәдәни чаралар vткәрv. Туклану да тулы һәм балансланган: яшелчә, жиләк-жимеш, сот продуктлары, ит, балык һәм башка файдалы продуктлар керә.

Флора Әхмәтжан кызы Шамонова житәкчелегендәге Рузаевка районы Татар Пешлә урта гомуми белем бирv мәктәбе яны “Орлята” балалар очен ике лагерь - 7 яшьтән алып 10 яшькә кадәрге укучылар контингенты белән кондезге сәламәтләндерv лагере һәм 14 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге укучылар контингенты белән хезмәт һәм ял лагере эше оештырылган. Оченче июньдә кызыклы лагерь тормышы иртәнге аштан сон лагерь сменасын ачу тантанасы белән башланып китә. Тантаналы линейка Россия Федерациясе Дәvләт флагын кvтәрv һәм РФ гимнын башкару тантанасыннан башлана. Коннен беренче яртысында балалар лагерь кагыйдәләре һәм законнары белән танышканнар, шулай ук каникул чорында куркынычсызлык техникасы буенча инструктаж vткәрелгән, эш планы турында фикер алышканнар. Балаларнын физик vсеше очен иртәнге зарядка һәм торле хәрәкәт уеннары vткәрелә. Лагерь балалары очен кызыклы интеллектуаль-кvнел ачу программасын Татар Пешләсе китапханәсе “БИТ-21” хезмәткәрләре әзерләп vткәргәннәр. Лагерь житәкчесе Сабина Руслан кызы Макунинадан лагерь эше турында сораштым. Ул: “Балалар интеллектуаль-кvнел ачу чарасында коллективны берләштерv уеннарында катнаштылар, әкият персонажларын искә тошерделәр, кvнеллеребусларны һәм табышмакларны чиштеләр, “Үзен турында сойлә” уенында рәхәтләнеп уйнадылар. Чара дәвамында югары эшчәнлек һәм яхшы психологик атмосфера сакланды.

Балалар кызыксыну, активлык, мостәкыйльлек кvрсәттеләр. Кон кvнелле һәм файдалы vтте, бик кvп унай эмоцияләр һәм яхшы кәеф алдылар.
Башка коннәр дә кон тәртибендәге план буенча vтә. Мәсәлән, Россия Федерациясенен дәvләт бәйрәме конендә, ә ул 12 июньдә иде, мәктәп яны лагерында ял итvчеләребез ил тарихы белән таныштылар. Балаларнын белем багажын Россия Федерациясе географиясе, анын флорасы һәм фаунасы, уникаль табигый байлыклары, милли ризыклары, субъектлары, халыклары һәм танылган Ватандашлары турында мәгълvмат

белән тулыландыру очен бу бик яхшы момкинлек иде. Әлеге бәйрәм хормәтенә Татар Пешлә клубы хезмәткәрләре асфальтта рәсемнәр конкурсы оештырдылар".
Менә шундый эчтәлекле һәм кызыклы чаралар тулы программаны тормышка ашырып киләләр алар.
Ләмберә районы Аксен урта мәктәбе "Тосле учлар" жәйге ял лагерында 11 нче кон! Иртә гадәттәгечә, Россия Федерациясе гимны һәм линейкасыннан башланган. Аннары "Остәл һәм кvчмә уеннар коне" vткән. Балалар зур рәхәтлек белән шашка, домино, мемо уйнаганнар, викторинада катнашканнар. Кон дәвамында Аксеново мәдәният йортында балалар очен цирк тамашасы узган. Коннен нәтижәсе - шатлыклар дингезе һәм бик яхшы кәеф. Шул ук конне, ягъни Россия коне алдыннан, Россия Федерациясе паспортына тышлыкларны һәм "Движение Первых" проекты кысаларында "Без-Россия гражданнары" билгеләрен тапшыру тантанасын Аксен урта мәктәбенен тәрбия буенча директор кинәшчесе Рушания Низаметдин кызы Шәмшетдинова vткәргән.
Ромодан районы Алтар урта мәктәбе яны балалар жәйге ял лагеренен бер коне ничек vткәнен белдек. Ул - ундvртенче кон иде, "Кояш бәрелvеннән ничек сакланырга" дигән темага сәламәтлек минуты белән башлана. Иртәнге аштан сон балалар ижтимагый-файдалы

хезмәт белән шогыльләнгәннәр, ә коннен икенче яртысында уен формасында жәяvлеләр очен юл хәрәкәте кагыйдәләрен кабатлаганнар.
Тагы бер лагерьнен бер коне турында сойлисе килә. Мәсәлән, Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбенен «Кояшлы нурлар» мәктәп яны лагерында 27 бала, башка мәктәп яны лагерьларында кvк, тvләvсез ял итә алар. Житәкчесе - Рузалия Рәстәм кызы Кандралеева. Шулай, 18 июньдә Латышовка урта мәктәбенен "Кояш нурлары" мәктәп яны лагеры тәрбияләнvчеләре очен Усыскино авылына һәм Инсар шәһәренә сәфәр оештырылган. Сәфәр алдыннан балалар стратонавтлар очышы турында фильм караганнар һәм Усыскино авылында урнашкан һәйкәл янында, Инсар шәһәрендәге "Туган якны ойрәнv" музеенда булганнар. Аннары балалар Инсар шәһәре М.Горький исемендәге паркта ял итеп, спорт тренажерларында да коч сынаганнар. Ә шул ук районнын Большая Поляна авылы топ мәктәбе яны "Салават кvпере" ял лагере балалары, янгырлы коннәрдә, кул эшләре белән шогыльләнеп матурлык тудырганнар. Россия халкы очен Боек Ватан сугышы башланган кон - "Хәтер һәм кайгы коне". Бу датага багышлап "Салават кvпере" ял лагере балалары, Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева житәкчелегендә, эчтәлекле "Якты хәтер: тарих белән очрашу" дигән чара vткәрәләр.
Менә шулай Мордовия мәктәпләре яны лагерьларында балаларнын жәйге ялы файдалы һәм кvнелле vтә.

Наилә НАСЫРОВА